| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**03.12.2019** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2630** |

Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү бирү тәртибе раслау турында

«Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүләрне билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Раслarга:
- Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү бирү тәртибен(1нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы- җитәкче урынбасарына әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы мәгариф оешмалары коллективларына җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы- җитәкче урынбасарына йөкләргә.
4. Әлеге карарның гамәлен 2019 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга .
5. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Д.С.Анисимовка әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В.Старостин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 3 декабрендәге 2630 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф оешмаларында(алга таба - Оешма) эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмәләр күләмен һәм түләү тәртибен билгели.

2. Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы түләүне, тиешле финанс елына әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетында карала торган акчалар исәбеннән башкарыла.

3. Әлеге тәртиптә педагогик хезмәткәр – яшь белгеч дип, һөнәри белем бирү оешмасын, югары белем бирү программалары – бакалавриат, специалитет, магистратура – буенча дәүләт аккредитациясе алган югары белем бирү оешмасын (алга таба – һөнәри белем бирү оешмасы яки югары белем бирү мәгариф оешмасы) беренче тапкыр көндезге формада тәмамлаган һәм һөнәри белем бирү оешмасы яисә югары белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлау елының 1 ноябреннәннән дә соңга калмыйча, һөнәри белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе нигезендә хезмәт шартнамәсе буенча оешмага эшкә алынган 30 яшькә кадәр булган зат таныла.

4. Педагогик хезмәткәрләргә- яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүне билгеләү хокукы түбәндәге оешмаларда бирелә:
мәктәпкәчә мәгариф оешмалары;
гомуми белем бирү оешмалары;
ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар;
өстәмә белем бирүне оешмалары.

5. Педагогик хезмәткәрләргә- яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү педагогик вазыйфада беренче өч ел дәвамында эшкә урнашу датасыннан билгеләнә.

Педагогик хезмәткәрләргә- яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүне билгеләү, туктату, озайту турындагы карар оешма боерыгы белән раслана.

6. Айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү алу өчен, әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән эшкә урнашу срогын үткәрүнең нигезле сәбәпләренә түбәндәгеләр керә:

документаль расланган вакытлыча хезмәткә яраксызлык;

Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә чакырылыш буенча вакытлы хезмәт итү яисә альтернатив граждан хезмәтен узу;

йөклелек һәм бала табу буенча отпуск, өч яшькә җиткәнче бала карау ялы.

Айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү, педагогик хезмәткәр – яшь белгеч хезмәт мөнәсәбәтләрен, вакытлыча эшкә сәләтсезлек тәмамланганнан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә чакырылыш буенча вакытлы хезмәт үткәннән яки альтернатив граждан хезмәте узганнан, йөклелек һәм бала табу буенча ял, өч

яшькә җиткәнче бала карау ялы тәмамланганнан соң, 60 көннән дә соңга калмыйча хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштергән шартта билгеләнә ала.

7. Хезмәткәрнең хәрби хезмәткә чакырылуына яисә хезмәткәрнең альтернатив граждан хезмәтенә җибәрелүенә бәйле рәвештә, хезмәт килешүе туктатылган очракта, айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү өч ел эшләү чоры чикләрендә, әгәр педагогик хезмәткәр – яшь белгеч Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш буенча хезмәт итү яки альтернатив гражданлык хезмәте тәмамланганнан соң, 60 көннән дә соңга калмыйча, хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштергән шартта кабат билгеләнергә мөмкин

8. Оешма белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүләр түбәндәге чорга туктатыла:

йөклелек һәм бала табу буенча ял вакытында, балага өч яшь тулганчы;

көндезге формада аспирантурада уку вакытына.

9. Педагогик вазыйфага башка оешмага күчкәндә эш вакытында 30 көннән дә артык булмаган вакытта тәнәфес рөхсәт ителә.

10. Педагогик хезмәткәрне - яшь белгечне эштән чыгарганда, санның яисә штатның кыскаруына бәйле рәвештә, алга таба педагогик вазыйфага эшкә урнашканда, эштә 60 көннән дә артык булмаган вакыт белән тәнәфес рөхсәт ителә.

11. Айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә “Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагог хезмәткәрләре вазыйфалары номенклатурасын, мәгариф оешмалары җитәкчеләре вазыйфалары номенклатурасын раслау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 8 августындагы 678 номерлы карары белән расланган мәгариф оешмалары җитәкчеләре вазыйфалары номенклатурасын раслау турында”гы 678 номерлы карары нигезендә педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары буенча билгеләнә.

12. Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү педагогик хезмәткәрнең – яшь белгечнең төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

13. Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү төп педагогик вазифа буенча һәм әлеге педагогик хезмәткәр – яшь белгеч тарафыннан эш бер үк вакытта башкару шартларында гамәлгә ашырылган вазифа буенча билгеләнә.

14. Хезмәт хакы ставкасы өчен атнага (елга) педагогик эш сәгате нормалары билгеләнгән педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times Hf / Hn,$$

биредә:

D - хезмәт хакы ставкасы өчен атнага (елга) педагогик эш сәгате нормалары билгеләнгән педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме, ләкин аена 1 111 сумнан артык түгел;

P - педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә атнага (елга) педагогик эш сәгате нормасы өчен 1 111 сум күләмендә стимуллаштыручы өстәмә түләү;

Hf - педагогик эш алып бару сәгатьләренең фактик саны;

Hn - хезмәт хакының төп ставкасы өчен сәгатьләр нормасы.

15. Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә (айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү әлеге тәртипнең 12 пункты белән билгеләнгән педагогик хезмәткәрләрдән - яшь белгечләрдән тыш) айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times t,$$

биредә:

D - педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме, әмма аена 1 111 сумнан да артык түгел;

P - педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә хезмәт хакы ставкасы өчен 1 111 сум күләмендә стимуллаштыручы өстәмә түләү;

t - фактгагы эшләнгән вакыт (ставкалар).

16. Педагогик хезмәткәрләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләр хисабына түләнә.

17. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-икътисадый хезмәте» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенең документлары (хисаплары) нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе ел саен 28 августка кадәр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәге документларны тапшыра:

- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча айлык стимуллаштыручы өстәмәләрне түләүгә субсидияләр бирү турында гариза;
- айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү өчен акча бирү турында гаризага кул куйган затның вәкаләтләрен раслый торган документ;
- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыклары белән расланган форма буенча Оешманың педагогик хезмәткәрләре - яшь белгечләренең реестрлары.